ГЛАВА
ЭБАЛАКОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
ЯБАЛАК АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

10 нчы ноябрь 2021 ел Ябалак авылы № 1

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү
һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районының Кече Кайбыч авылында
гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законының 25.1, 56 маддәләре,«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе,Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ябалак авыл җирлеге Уставының 22маддәсе нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. 2021 елның 23 ноябренә 10 сәгать 00 минутка Кече Кайбыч авылы,Мәктәп урамы,10А адресы буенча урнашкан башлангыч гомуми белем бирү мәктәбе бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ябалак авыл җирлеге Кече Кайбыч авылында **үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын** билгеләргә.

2. 2021 елның 24ноябренә 11 сәгать 00 минутка Кече Кайбыч авылы,Үзәк урамы,52 нче йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ябалак авыл җирлегенең Кече Кайбыч авылында **үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын** билгеләргә.

3 2021 елның 24 нояберенә 13 сәгать 00 минутка Кече Кайбыч авылы, Үзәк урамы, 2 нче йорт янында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ябалак авыл җирлегенең Кече Кайбыч авылында **үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын** билгеләргә.

4. 2021 елның 24 нояберенә 14 сәгать 00 минутка Кече Кайбыч авылы, Урман урамы,4 нче йорт адресы буенча урнашкан мәчет бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ябалак авыл җирлегенең Кече Кайбыч авылында **үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының дүртенче этабын** билгеләргә.

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2022 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының яшәү урыны буенча Ябалак авыл җирлеге Кече Кайбыч авылы территориясендә теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

*а) җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:*

- материаллар сатып алып, урам утларын ремонтлау;
- җирлектәге торак пунктлардагы чүплекләрне чистарту;
- материаллар сатып алып җәяүлеләр күперен ремонтлау;

*б)авыл җирлеге чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү:*

- янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү өчен материаллар сатып алып, табигый су чыганакларына керү юлларын тәртипкә китерү эшләре;

*в) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:*

- материаллар сатып алып, юлларны норматив хәлгә китерү».
- җирлекнең торак пунктлары чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту;

*г) ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту;*

- зиратларны чистарту һәм төзекләндерү, материаллар сатып алып контейнер мәйданчыкларын җиһазлау.»

« РИЗА» «КАРШЫ»

6. Ябалак авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән әлеге карарны игълан итәргә һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru), Кайбыч муниципаль районы Ябалак авыл җирлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат- телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: https://ebalak-kaybici.tatarstan.ru

7. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ябалак авыл җирлеге Башкарма комитеты гражданнар җыенын үткәргәндә Ябалак авыл җирлеге территориясендә яңа коронавирус йогышы (GOVID-19) авыру очракларын кисәтү һәм таратуга каршы профилактик,санитар-эпедемик чараларының үтәлешен тәэмин итәргә.

8. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Ябалак авыл җирлеге башлыгы Гыйзәтуллина М. Ф

Совет Эбалаковского сельского поселения Ябалак авыл җирлеге Советы